БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18 гыйнвар 2022 ел №100

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 апрелендәге 116-ФЗ номерлы Федераль законга (2021 елның 30 декабрендәге редакциядә), «2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 13 декабрендәге 1222 номерлы карарына туры китереп һәм прокуратураның 2021 елның 14 декабрендәге 02-08-02-2021 номерлы протесты, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар бирде:

1. Балтач район Советының 2016 елның 23 декабрендәге 68 номерлы карары белән (2017 елның 24 июнендәге 88 номерлы, 2018 елның 1 ноябрендәге 151 номерлы, 2020 елның 9 октябрендәге 10 номерлы үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 19.1 пунктындагы 2 пунктча үз көчен югалткан дип таныргa.

1.2. Нигезләмәнең 22.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22.1. Муниципаль хезмәткәрләрнең акчалата хезмәт хакы ул биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасы нигезендә муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи окладыннан (алга таба - вазыйфаи оклад), тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәдән, муниципаль хезмәтнең аерым шартлары өчен вазыйфаи окладына айлык өстәмәдән, аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне

үтәгән өчен премияләрдән, айлык акчалата бүләкләү, классы чин өчен айлык өстәмәдән, еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүдән, матди ярдәмнән, хезмәт көне нормалаштырылмаган шартларда эшләгән өчен айлык компенсация түләүдән, төп хезмәт вазыйфаларына хокукый актларга һәм хокукый актлар проектларына хокукый экспертиза үткәрү, хокукый актлар проектларын әзерләү һәм редакцияләү һәм аларга юрист яки башкаручы сыйфатында виза салу кергән муниципаль хезмәткәрләргә айлык акчалата түләүдән (юридик эш өчен өстәмәдән), профильле гыйльми дәрәҗә өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәдән тора.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасары Н.Н.Сабирҗановка йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе — Р. Р. Нотфуллин